**СОВЕТ БИКБУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКБАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР №1 24 январь 2025 ел

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.10.2023 ел № 2 карарга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында»2014 елның 30 октябрендәге №82-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы ,«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»12.07.2024 ел № 176-ФЗ Федераль законы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРА:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.10.2023 ел № 2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасының 2 абзацында«, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«6) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент.»;

1.3. 2 пунктның 1 пунктчасының 3 абзацында «һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л. Н. Мәрдәмшина